Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының
КАРАРЫ

2021 елның 26 октябре №15/6

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлегендә җирдән
файдалану һәм төзелеш алып бару
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 июлендәге 8/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районының 2021 елның 4 октябрендәге 4 номерлы Татар Ялтаны авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре буенча комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

*Карар бирә:*

1. Чистай муниципаль районы «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясе шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә, «Индивидуаль торак йортлар белән төзелеш зонасы» Ж-1 территориаль зонасы чиген үзгәртү һәм Кооператив ур., з/у 5В, Татар Ялтаны авылы чикләрендәге территорияне, шул исәптән кадастр номеры 16:42:120102:477 булган, 720 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген, «Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона» ОД1 зонасына кертү өлешендә (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны җирлек халкы күпләп җыела торган урыннарда игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татар Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы Гарифуллин Р.Р.

2021 елның 26 октябрендәге 15/6 номерлы карарына
1 нче кушымта

Чистай муниципаль районы «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

